**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегенең Генераль планы (үзгәрешләр кертү) проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2023 елның 15 декабре

Халык алдында тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы - Совет рәисе инициативасы белән үткәрелде, 2023елның 8 ноябрендәге 122-РС номерлы карар белән билгеләнде.

Чирпы авыл җирлегенең Генераль планы проекты (үзгәрешләр кертү) буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2023 елның 8 ноябрендәге 122-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2023 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2023 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;
3. 2023 елның 10 ноябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 ноябрендәге 10790/исх.номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Ачык тыңлаулар башлану турында 2023 елның 10 ноябрендәге 10790/исх.номерлы хәбәр басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2023 елның 13 ноябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегенең рәсми сайтында;
2. 2023 елның 15 ноябрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);
3. 2023 елның 13 ноябрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Зотин Рушан Юсупович - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге башлыгы.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2023 елның 14 декабрендә Чирпы авыл җирлегенең Генераль планы (үзгәрешләр кертү) проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 9 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр.

Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре:

1.Халык тыңлауларын узган дип тану;

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең Генераль планы(үзгәрешләр кертү) проектын, 2023 елның 14 декабрендәге ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнар нигезендә әлеге нәтиҗәдән өземтәләр бирергә.

Ачык тыңлаулар рәисе __________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре _________________________ Зотин Р.Ю.